**Татарстан Республикасы Азнакай район**
**Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 210-24 2023 елның "18" апреленнән

«Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны, идарәче компанияләрне һәм индивидуаль эшкуарларны арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән азат итү турында» 2021 елның 26 августындагы 70-9 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай район Советының карарына үзгәрешләр кертү хакында

Инвестицияләрне җәлеп итү өчен шартлар тудыру, Татарстан Республикасының «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә өстәмә эш урыннары булдыру максатларында,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. «Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны, идарәче компанияләрне һәм индивидуаль эшкуарларны арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән азат итү турында» 2021 елның 26 августындагы 70-9 номерлы Татарстан Республикасы Азнакай район Советының карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «2018 елның 01 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр чорга» сүзләрен «2023 елның 01 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://aznakayevo. tatar.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына һәм бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин